# Караш

…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№5 2016. ФЕВРАЛЬ


***15 нче февральдән мәктәптә «Поэзия һәм проза айлыгы» башланып китте. Уку елы барышында мөгаен бу иң кызыклы айлыкларның берседер. Чөнки безнең мәктәптә азмы-күпме дәрәҗәдә каләмен тибрәтмәгән укучы юктыр. Кемдер шигырь яза, кемдер әкият-хикәя, ә кемдер бөтенләй яңа төрле иҗат белән шөгыльләнә. Ләкин үз иҗатының җимешен башкалар белән уртаклашмый. Алай ярамый, әйдәгез, бергәләп укыйк.***

***Китап***

Яктылыкка юл күрсәтер,
Начарлык тәкъдим итмәс.
«Тәртипсезлек сукмагында
Йөрмә, - дияр, - кирәкмәс!»
Кирәк булса булышыр ул,
Авыр хәлдән чыгарыр.
Аптыраган кешегә
Ярдәм кулын ул сузар.
Белем диңгезендә йөзә
Китап белән һәр бала.
Син дә дустым калышма,
Китаплар укып кара.

***Бер теләгем.***

Әбиемнең кулларында гел,
Тәсбих я Корьән күрәм.
Шул Корьәнне укый миңа,
Шуңа күп нәрсә беләм.
Үрнәк алам әбиемнән,
Аның кебек булырга,
Корьән нурлары яктырткан
Тугры юлдан барырга.

***Актәпием син минем…***

Актәпием – минем этем,
Ул әле бик кечкенә.
Аллә шуңа күрә дәме
Таный тик мине генә.
Көчегемне бик яратам,
Ул да мине ярата.
Җырлар җырлап алыйм әле
Актәпигә карата:
«Актәпием бик кечкенә,
Кечкенә дә, төш кенә.
Язлар үтәр, җәйләр җитәр,
Син тизрәк үс кенә.»

***Роза гөлем***

Берчак бакчага кердем,
Роза чәчәген күрдем.
Ак иде ул, саф иде,
Бар бакчага ямь бирде.
Ләкин моңсу иде ул…
Нидер эндәште сыман.
Башы да түбән иелгән
Әллә ни булган сыман.
Карап торгач аңладым мин:
Дустын өзгәннәр икән.
Канатын каерганнар,
Ялгызын калдырганнар.
Эвелина 5 нче сыйныф.

***Беренче кар.***

**Беренче кар, нигә соң син**
**Явасың да эреп бетәсең?**
**Җирдә булган бөтен матурлыкны**
**Үзең белән алып китәсең?**
**Беренче кар…**
**Нинди матур мизгел.**
**Онытылмас кыска хәтирә.**
**Күңелдәге бөтен шигъри хисләр**
**Синең белән бергә үрелә…**
**РАНИЯ 11 нче сыйныф.**

***Соңгы сүз.***

**Сагынып көттем сине, бәгърем.**
**Өзгәләнде гашыйк йөрәгем.**
**Тик килмәдең көткән чакларымда,**
**Алдадың бит мине, кадерлем.**
**Бер күрүдә гашыйк булдым сиңа,**
**Сихерләде назлы күзләрең.**
**Бүтән карашларны тойсам да мин,**

**Тик синекен,**
**Тик синекен генә эзләдем.**
**Хәзер инде «сөям» дисәң дә**
**Йөрәктәге бозлар эремәс.**
**Сине уйлап инде саташмыймын.**
**Тик яралар гына терелмәс.**
Айгөл С. 11 нче сыйныф

**Киңәш.**

**Мәхәббәт әлбәттә, бөек хис.**
**Дөнья мәхәббәткә корылган.**
**Сөю учагында ялкынланып**
**Күпме гашыйк йөрәк кабынган**
**Мәхәббәтнең кайнар ялкыннары**
**Боз күңелне хәтта эретә;**
**Һәр кешене, һәр йөрәкне бу хис**
**Көтмәгәндә кинәт үзгәртә.**
**Һәм дөньясы кинәт үзгәрә аның,**
**Ул бәхеттән оча күкләргә.**
**Тик кайчакта җавапсыз хисләрдән**
**Боз сөңге кадала йөрәккә.**
**Мәхәббәткә ышанмаучылар аз.**
**Карама аларның сүзенә.**
**Килер көн – Амур аткан уклар**
**Тияр аларның да күкрәгенә.**
**Кыюрак бул, бәхет үзе килми.**
**Аны кирәк яулап алырга.**
**Сөйгәненнең йөрәгенә юл тап,**
**Үз бәхетең синең кулларда.**
**Гөлназ С. 11 класс**

***Ак һәм кара***
(нәсер)

Күзләр моңсу. Нигә шулай икәнен һәркем аңлый инде. Табигать кышкы йокысына әзерләнә, кошлар җылы якка китеп беткән, бар матурлыкларын яфрак шәлләре белән каплап торган агачлар да шәп-шәрә калганнар. Үзләренең бу тыйнаксызлыкларыннан оялгандай көзге җилгә нидер әйтергә телəп әй өзгәләнәләр, гүелдиләр… Ләкин көзге җил аның саен аларның шул шәрә ботакларын һаман кага, селкә. Әлегә ул хуҗа икәнлеген күрсәтә. Калын болытлар арасыннан берничә мизгелгә генә караган кояш: «Нишлисең, җирем, әле исән-саумысы-ы-ың?» дигәндәй, бер елмаеп куя да кабат болытлар арасына кереп югала. Әйтерсең лә, ул болытларның тотыгы. Тирә-юньдә бөтенесе дә ак һәм кара төсләрдән генә тора. Хәер, агы инде аның үткән атнада явып, эреп бетә алмыйча калган кар өемнәре генә. Кара җир, каралып беткән чирәм, карасуланып өлгергән яфраклар… Табигатьнең эч пошыргыч ямьсез мәле… Күзне иркәләрдәй ачык төсләр юк. Хәтта ак кием кигән кеше дә сәерсенү уята: ак каргадай шул карада аклыны кигән… Тизрәк кар яусын иде, бу каралыкны үзенең аклыгы белән капласын иде. Нинди күңелле булыр иде. Бит аклык гел шатлык кына китерә: яңа елда ак кар ява, юлчыларга ак юл телиләр, туйда да кәләш ак киемнән, бәйрәмнәрдә дә аклы кием кияләр.

Уйга калдым. Аклык шатлык билгесе булгач, нигә соңгы юлга ак кәфенгә төреп озаталар? Һәм нигә кара кайгылар башта ак чәч булып шыта?? Ни өчен күпереп пешкән ак ипи үзенең башлангычын кап-кара җирдән ала? Сораулар күп. Җавап бирер кеше генә юк. Кара төндә, кара юлдан берүзем барам… Тормышыбыз гел шул буяуга гына бай кебек тоела башлый…

Одна такая

***Сорыбайның дәресе.***
(Чын әкият)

Мин монда ничек килеп эләктем икән? Нинди матур урын… Карале, бананнар шулай күп буламы икәнни? Ә мандарин куаклары җиргә сыгылган. Эшләр пешә болай булгач… Алай да кайсы җирләр икән бу?

- Бу минем биләмәләр.

Артымнан ишетелгән тавышка сискәнеп борылып карасам да, тавыш иясен генә күрмәдем.

- Шулаймыни, бик матур урыннар. Ә мин монда ничек килеп эләктем соң?

- Әйе, монда минем җирләр, монда чыннан да бөтенесе матур, камил, үзегез пычратып бетергән урманнарыгыз, сазлавыкка әйләндергән күлләрегез түгел инде.

- Кем белән сөйләшәм соң мин? – дип аптырап тирә-ягыма карадым, ләкин әле һаман тавыш иясен генә күрмәдем.

- Мин – бүре.

- Б-б-бүре? – мин чак кына куркудан егылып китмәдем, ә шулай да кыюлыгым кире үземә кайтты.

- Ярар, шыттырма, бүреләр сөйләшә белми. Кем соң син?

- Бүре дидем ич, Сорыбай.

Шулчак алдымда олыгаем зур бүре пәйда булды. Курыкмадым дип әйтә алмыйм, курыктым, хәтта ки очкылык тота башладым.

-Нишләп сөйләшәсең син?

-Ха-ха-ха. Нишләп сөйләшмәскә, безнең бүре халкы гомер-гомергә сөйләшә белә бит, кешеләрне дә сөйләшергә без өйрәттек. Мәнә татарлар шуңа күрә бүреләрне элгәрәк заманнарда бик хөрмәт итә иде, ә хәзер юк, үзгәрделәр.

-Ярар, шулай да булсын да ди, ә мин менә нигә монда?

- Нигәме? Акыл өйрәтергә! Чөнки син бик яшьли алдашырга өйрәнмәкчесең. Менә нигә син тренировкаларга йөрм и башладың, синнән бик әйбәт спортсмен чыгар иде.

- Ни бит, авырыйм, әле менә аякларым да авырта, эчем дә сыкрап тора…

- Я, я, алдашма. Синең бер җиреңдә авыртмый.

Сорыбай шул чак юкка чыкты. Китүе хәерле дип, мин дә рхәтләнеп тирә-ягымны күзәтергә керештем, куагыннан гына бер мандаринны өзеп алдым, кабарга гына җыенган идем, артта нindидер тавыш ишетелде. Ка-ра-сам, малай, алагаем зур аю минем өскә килә. Аны моны уйлап торыр чак түгел, әй йөгерәм, әй йөгерәм. Бу кадәрле тиз итеп минем кросста йөгергәнем булмады. Күпме дер вакыттан соң, тезләремне билемә урап, йөрәгемне учыма кысып борылып карадым. Аю әле мине куып тотмаячак, чөнки мин дә, аю да бер урында йөгереп торганбыз икән. Минем аяк астында чирәм әйләнеп кенә тора икән. Туктадым, аю исә мине куып тотты да, шундый итеп колакка салып җибәрде, һәм Сорыбайга әверелде. Әлбәттә, мин кабат аның акыл сатуын тыңлап торырга җыенмый идем, аннары шулай алдануымнан да көлдерергә теләмичә ерак түгел күренеп торган күлгә юнәлдем. Күл бик тоныкиде, Байкал күлен картада гына күргән булсам да, әлеге күл миңа нәкъ шул Байкал күле кадәрле тоелды. Чиста суны эчеп алгач, коенасы килеп китте. Ике дә уйлап тормыйча, суга кереп тә киттем. Ләкин ләззәтем озак бармады, янымда гына коточкыч акула пәйда булды. «Бусы да Сорыбайның бер-бер-Хәйләсе инде», дип мин качмаска да уйлап куйган идем. Ләкин, ышаныгыз, чын акула кинодагыларыннан күпкә куркынычрак икән, үзеннән-үзе ярга омтылдым. Гел-гел алдаулар, зарланулар, физкультура дәресләреннән ялган справкалар белән качып йөрүләр үзенекен иткән – мин бик начар йөздем. Акула мине бик тиз тотты, тотты һәм йотты…. дигәндә

кинәт кенә ярда басып тора башладым. Минем алда Сорыбай елмаеп тора.

- Р-рәхмәт, Сорыбай.
- Рәхмәтен рәхмәт инде, ә менә син минем ни әйтергә теләгәнемне аңладыңмы икән?
- Аңладым бугай. Хәйләләмәскә кушасың. Карале, Сорыбай, Ә шулай да кешеләрнең сәламәтлеге сиңа нигә, спорт белән шөгыльләнсәк, шөгыльләнмәсәк сиңа ни файда?
- Мин бөтен тереклек ияләренең патшасымын. Үз хезмәтчеләремнең сәламәт блуын телим мин. Маймыллар бит әнә элеккечә сикерәләр дә, чабалар да, үрмәлиләр, ә менә сез – кешеләр көннән-көн яшәү бәхетен тәмле ашап, озак йоклау да гына күрәсез. Ә бит иң зур бәхет – сәламәтлек. Дусларыңа да бу хакта аңлат.
- Тыңлап торырлар ди.
- Тыңламасалар, берәм-берәм яныма дәрескә чакырырмын, ышаныррлар, тыңларлар.
- Кызым! Кызым, дим. Уян инде, әнә син яраткан бәлешне пешердем, ашап алыйк.
- Юк әле, әнкәй, мин очтым, тренировкага барам. – шулай дип сикереп тордым, күргәннәрем төш кенә булса да, өнгә ошаган иде.
- Чү, балам, эчең дә авырта, аякларың да сызлый…
- Бетте, терелдем инде. - ашыга-ашыга юындым. – Мин киредән тренировкага йөри башлыйм. Менә күрерсең – бар да искиткеч булачак!

«Сорыбай, ишетәсеңме, синеңчә булачак. Мин ялкаулыкны куып таратам. Ишетәсеңме?»

Ранис 5 нче сыйныф.

## Серле ярдәм яки кайтарылмаган бурыч.

Зәринә барысын да бер минут эчендә югалтты: сумкасын да, телефонын да, акчасын да... Һәм чит шәһәр уртасында япа-ялгызы басып калды. Аның тамак төбенәниндидер бер авыр төер килеп утырды, борын яфраклары нәкъ сабый балаларныкы кебек алсулана төште.

Ул, үзе дә кая таба юнәлергә белмичә, турыга атлады да атлады. Юк, юл уртасында туктап, узып баручыларның аптыраулы карашларына, игътибарына дучар буласы килмәде аның.

Әмма ирексездән атылып чыккан яшьләре Зәринәнең зур коңгырт күзләрен чылатып өлгергән иде инде…

Читләргә күрсәтергә теләмичә, бертуктаусыз уудан кызарган, әрнеп беткән күзләрен яшерә-яшерә, һаман саен кайнар яшьләренә буыла-буыла алга атлады ул.

Һәрбер адым ясаган саен, аның башына бер-бер артлы алышына-алышына катлаулырак, житдидән житди сораулар килә торды.

Аңа әлеге хәл кйчандыр булган һәм бары хәзер кабатлана гына кебек тоелды. Әйе, бала чагында күрше Мирсәйләрнең алма бакчасыннан элдерткәндә, койма аша сикереп чыгыйм дигәндә генә, күлмәге эләгеп калып яртылаш умырылып төшкәннән соң, күрше-тирә малайлар аңардан рәхәтләнеп, эчләре катканчы көлеп калганнар иде, ә ул, нәкъ шулай сулкылдый-сулкылдый, алны-артны белмичә өенә таба йөгереп кайтып киткән иде.

Ләкин хәзер шулай өйгә кайтып буламы соң? Ул бит бөтенләй чит, таныш булмаган урам аша, чит кешеләргә этелә-төртелә каядыр бара да бара...

Инде киң урамнар буйлап бер-бер артлы тонык кына фонарь утлары яктыра башлады, күккә ниндидер бер эч пошыргыч зәңгәрсу төстәге юрган җәелгәндәй караңгылата башлады, ә офыкта алтынга манчылган каурый сыман нәни болытларын иярт
еп, кояш, саубуллашу нурларын көчсез генә сирпеп, тирән йокысына ашыга иде инде. Өметсезлек белән бер рәттән Зәринәнең куңелен тирән оялу хисе чолгап алды.

Шушы гаҗәеп матур күренешне ул хәзер генә күрә, хәзер генә аның күңелендә шундый соклану хисе туганга оят иде аңа. Шушы дөнья мәшәкатьләре белән кузе томаланып, тулысынча диярлек укуга, институт тормышына чумып үзен һәркөн чолгап тора торган матурлыкны исеннән дә чыгарган икән ул. Кызның күңеле жиңеләеп киткәндәй булды,ул якын тирәдәге эскәмиягә барып утырды. “Нишләргә?”

Ул: "Юк. Юк. Шәһәр бит ул болай гына зур кебек тоела, ә чынлыкта....Табарлар, иртәгә ук табарлар, Аллаһ боерса! Аннан соң телефонны, акчаны урлаган каракны да кулга алырлар. Бар да җайланыр. Бар да яхшы булыр. Я Раббым, ярдәмеңнән ташлама!" - дигән уйлары белән үз-үзен ышандырырга, тынычландырырга тырышып маташканда, көне буе йөреп талчыккан аякларының авыртуларын үзе дә сизмәс дәрәҗәгә житеп, яшьләнеп каткан керфекләрен авыр гына йомган килеш тирән йокыга талды.

-Әй, кызым, уян! Уян дим... Үлмәгәнсеңдер бит? Әллә саңгыраумы син? Исереккә дә ошамагансың...

Зәринә саңгырау түгел, ишетә. Ләкин аның күзләрен ачасы килми. Монда, йокы дөньясында, ничектер алай ук куркыныч түгел... Ә ачмыйча ярамый.

-Мин ишетәм, мин арыдым гына. Бик арыдым.

- И бала, арысаң кайтып ял ит, килешми кыз балага төнлә болай йөрүе. Әнә акчаң да төшкән, шәһәр ачык авызларны яратмый.

“Акча? Төшкән? Төш күрәм ахры...”

Зәринә авырлык белән күзен ачты. Каршысында бик мөлаем йөзле бабай аңа елмаеп карады.

-Хәлең ничек?

“Хәлем? Ничекләр елап жибәрмичә түзәргә соң?”

-Акчаң төшкән, ал, бала. Тәртипле балага ошагансың, болай мажара эзләп йөрмә.

Зәринә аяк астына карады, анда урталай бөкләнгән кызыл биш меңлек ята иде... Йокыдан айнып бетмәгән кыз акчага иелде.

- Бу минем акча түгел... Мин...

Ләкин Зәринә акчаны тотып турайганда, аның янында берәү дә юк иде. Әнә тегендә бер кыз этен йөртә, теге эскәмиядә егет белән кыз үз мәхәббәт дөньяларында. Ә бабай юк. Зәринә саташам ахры дип күзләрен чытырдатып йомды, акчаны учына кысты, әбисе өйрәткән догаларны кабатлады. Юк, ул уяу икән, акча да кулында...

... Бу акча аңа өйгә кайтырга да, документларын юлларга да җитте. Ничә еллар узса да, Зәринә әлеге вакыйгага аңлатма таба алмады. Кем булды бу карт, әлеге акча каян килде? Әбисенә сер итеп кенә сөйләгән иде, әбисе аңа: "Хозыр Ильяс булгандыр ул, кызым, чарасызлыгыңнан ярдәм иткәндер", - диде. Ә Зәринә күңелендә һаман шул вакыйганы йөртә, бурычны бит аны кайчан да булса кайтарасы....

Саматова Айгөл 11 сыйныф

**Күтеп алган яңгыр.**

**Борын-борын заманда бик тылсымлы болыт яшәгән ди. Нинди генә авырлыклар очраса да, үзенең тылсымын эшкә җиккән ди. Ләкин тылсым көчен үзенә генә түгел, ә башкаларга да ярдәм иткәндә кулланырга уйлаган. Шулай итеп, башкаларны күбрәк шатландырырга теләгән.**

**Шулай бер көнне агым уңаена акканда, җәелеп яткан авыллар, шәһәрләргә игътибар иткән. Бу авыллар, шәһәрләр бик боек булып күренгән аңа. Бигрәк тә авыллар. Яхшылап караса әле җәй булуга карамастан анда барлык яшеллек көеп беткән. Тереклекләр башларын аска иеп, моңсуланганнар. Күрәсең монда күптән яңгыр яуганы юк икән. Тиз генә үзеннән алга киткән иптәшләрен куып җиткән хәлне аңлатып, ярдәм итәргә теләвен әйтткән. Бу эштә аларның да ярдәм итүләрен үтенгән.**

**- Безнең яңгыр яудырырга бер дә теләгебез юк, - дип җавап биргәннәр аңа.**

**- Халыкны мондый хәлдә ташлап китәргә ярамый, алар бит бездән ярдәм көтеп, барысы да күккә төбәлгән, - дигән тылсымлы болыт.**

**- Соң күрсәт тылсымыңны, әгәр хәлеңнән килсә, - дигәннәр барсы бер тавыштан.**

**Тылсымлы болыт монда үзенең генә хәле җитмәячәген, яңгырның күп җиргә кирәклеген аңлатса да аңардан көлгәннәр генә, янәсе мактанчык, булдыксыз.**

**- Юк минем тылсымым белән беркайчан да мактанганым юк. Ул сәләт миңа ата- бабадан калган.**

**- Я соң, күрсәт сәләтеңне,- дип юлларын дәвам иткән көнче болытлар.**

**Тылсымлы болыт тәвәкәлләгән. Аның бик тә, бик тә ярдәм итәсе килә. Ул юлыннан борылып кирегә йөзәргә керешә. Башка болытларга бәрелә, сугыла, аңа юл бирмиләр. Аларның бәрелүеннән көчле күк күкрәү барлыкка килә. Ә бу халыкта тагын өмет уята.**

**Болытлар үз юлыннан гына бармаучы бу болытны орышалар, анардан көләләр. Ә тылсымлы болыт алар белән көрәшә-көрәшә корылык хөкем сөргән бу урынга килеп җитә. Тылсымлы сүзләрен кабатлый-кабатлый тирә -якка кулларын селкә. Бу селтәүләрдән йолт-йолт яшен яшни һәм ниһаять, яңгыр яварга тотына. Әкрен генә, тәмен белеп кенә бик озак ява яңгыр. Тылсым көченә ышанмаучылар да гаҗәпләнерлек була бу.**

**Барча тереклек туйганчы су эчә, рәхмәт укый. Ә тылсымлы болыт башкаларга ярдәм итүенә сөенеп бетә алмый. Әле һаман шулай тилмереп утыручылар юкмы икән дип каранып йөри ди.**

**Русинә 5 нче класс**

**Кышлар үтә язлар көтеп,**
**Язы уза җәй сөйләп,**
**Җәе дә калышмый аннан,**
**Көзләре үтә эшләп.**

**Көзе тагын алга чаба,**
**Тиргибез аның сазын,**
**Имеш яусын тизрәк ак кар,**
**Чистарак була кышын.**

**Әнә шулай үтә вакыт,**
**Тормыш гел алга чаба.**
**Язмыштан узмыш юк дип,**
**Кемдер зарланып тәмен таба.**

**Кара уңга, кара сулга.**
**Дөнья гүзәл, ул синеке.**
**Үзгәрт, җимер. кабат төзе,**
**Тормышың үзеңнеке!!!**

**РАНИЯ 11 нче класс**